**СОВЕТ ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул. Центральная, д.45Б,
с. Шахмайкино,423183

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШАХМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Үзәк урам, 45Б
Шахмай авылы,423183

тел.: (8-84348) 3-84-96, факс: (8-84348) 3-84-46, Shah.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2026 елның 24 апреле № 8-23

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә кермәгән территориясендә яшел үсентеләрне утырту, карап тоту һәм саклау тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Уставы нигезендә, Шахмай авыл җирлеге территориясендә экологик ситуацияне яхшырту, яшел үсентеләрне саклау өчен җаваплылыкны арттыру, яшел хуҗалык алып баруның төп мәсьәләләрен тәртипкә салу максатында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне утырту, карап тоту һәм саклау тәртибе турындагы нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелгән).
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге башлыгы Н.М. Илалова

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «НОВОШЕШМИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН «ШАХМАЙКИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
р 05-11944/14
СОВЕТ ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Кушымта
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге Советының
2026 ел 24 апрель № 8-23 карарына

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне утырту, карап тоту һәм саклау тәртибе турында нигезләмә

1. Гомуми өлеш

1.1. Яшелләндерелгән территорияләр җирлекнең табигый комплексы һәм яшеллек фонды территориясенең состав өлеше буларак үсемлекләр белән беррәттән табигатьне саклау, әйләнә-тирәне саклау, ял итү, мохит формалаштыру һәм санитар-яклау функцияләрен үтиләр.

1.2. Яшелләндерелгән территорияләрнең урыны һәм чикләре тарихи барлыкка килгән планировканы исәпкә алып һәм табигый компонентлар-рельеф, акваторияләр һәм яшел утыртмаларны исәпкә алып билгеләнә.

1.3. Яшел үсемлекләрне утырту, карап тоту һәм саклау Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Башкарма комитетына йөкләнә.

1.4. Яңа төзелешкә яшелләндерелгән территорияләр булдыру буенча комплекслы эшләр керә. Яңа төзелештәге эшләрнең барлык төрләре дә билгеләнгән тәртиптә эшләнгән, килештерелгән һәм расланган проект документациясе нигезендә башкарыла.

1.5. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге (алга таба – авыл җирлеге) территориясендә яшел үсентеләрне агымдагы карап тоту эшләренә агач төпләрен кисеп, коры, авария хәлендәге һәм декоратив төсе югалган агач һәм куакларны аудару; үсемлекләрне санитар кисү керә.

1.6. Яшелләндерү объектларын карап тоту - яшеллекне һәм яшелләндерелгән территорияләрне төзекләндерү элементларын карау буенча комплекслы эшләр ул. Яшел үсенлекләрне карап тоту түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- агымдагы ремонт;
- агач һәм куаклыкларны карау буенча эшләрне – үсемлекләрне өстәмә тукландыру, сугару, йомшарту, утау, саклау, тамыр системасын җылыту, салкынга бирешүче токым куакларны бәйләү һәм чишү, җылы яратучы үсемлекләрне ышыклау һәм каплау (ул очрактагы барлык булган эшләр белән), ашламалар, чүп-чарларны төяү һәм бушату, корыган һәм авария хәлендәге агачларны кисү һ.б.ны;
- чәчәклекләрне карау буенча эшләрне – орлык чәчү, үсенте һәм суганчаларны утырту, сугару, йомшарту, утау, өстәмә тукландыру, үсемлекләрне саклау, чүп-чарны җыю һәм башка эшләрне;
- чәчәк вазаларын карау буенча эшләрне.

2. Яшел үсенлекләрне барлыкка китерү.

2.1. Территорияне әзерләү

2.1.1. Территорияне әзерләү эшләрен җимерелергә тиешле корылмаларны, агач төпләрен, төзелеш материаллары калдыкларын, чүп-чарны чистартудан башларга кирәк:

| Объект | Агач күчәреннән объектка кадәр, м. | Агач көүсәсеннән объектка кадәр, м. |
|---|---|---|
| Бинаның, корылманың тышкы стенасы | 5,0 | 1,5 |
| Тротуар кырые, бакча юлы | 0,7 | 0,5 |
| Урамның йөрү өлеше кырые | 2,0 | 1,0 |
| Яктырту челтәренең таянычы | 4,0 | |
| Табан һәм стеналарының эчке кыры терәге | 3,0 | 1,0 |
| Газүткәргеч: тышкы торбалар өчен | 2,0 | - |
| Газүткәргеч: полиэтилен җир асты торбалары өчен (торбаның төрле якларыннан) | 3,0 | - |
| Суүткәргеч, дренаж | 2,0 | - |
| Көч кабеле, элемтә кабеле | 2,0 | 0,7 |

Искәрмәләр:

1. Китерелгән нормативлар ябалдашларның диаметры 5 метрдан да артмаган агачларга карый һәм, димәк, зур диаметрлы агачлар өчен арттырылырга тиеш.
2. Агач һәм куаклар утыртканда биналарның, корылмаларның, балалар учреждениеләренең тышкы стеналары янында инсоляция һәм табигый яктырту норматив дәрәҗәләрен үтәргә кирәк.

## 2.2. Яшел үсентеләрне карап тоту

2.2.1. Яшел утыртмаларны дөрес карап тоту буенча төп чараларның берсе булып ябалдашларны кисү тора. Санитария, яшәртү, формалаштыру кебек кисү төрләре бар.

2.2.2. Ябалдашларны санитар кисеп алу иске, авыру, кипкән һәм зарарланган ботакларны, шулай ук ябалдаш эченә яки бер-берсенә якынайган ботакларны кисүгә юнәлдерелгән.

Шулай ук үзәк көүсәдән очлы почмак яки вертикаль (пирамидаль формалардан тыш) өскә таба чыгып торучы бәбәкләр дә, аларны сынуга һәм көүсәдә яралар барлыкка китермәслек итеп, киселергә тиеш.

Санитар кисеп алуны вегетация дәвере буена ел саен үткәрергә кирәк. Ләкин зур күләмдә зур ботакларны бер үк вакытта кисү уңайсыз, шуңа күрә аларны акрынлап, елына 1-2 ботакны алып ташлау яхшырак.

## 2.3. Чәчәк түтәлләре ясау

2.3.1. Чәчәк түтәле - бу геометрик формада яки ирекле формада берьеллык, икееллык яки күпьеллык үсемлекләр утыртылган участок. Бу яшелләндерү объектының иң декоратив элементларының берсе.

## 2.4. Чәчәк түтәлләрен карап тоту

2.4.1. Чәчәк түтәлләрен тиешле тәртиптә карап тоту түбәндәгеләрдән тора: үсемлекләргә су сибү һәм коендыру, туфракны йомшарту һәм чүп үләннәрен утау, чәчәк атып бетергәннәрен кисү, корткычлардан һәм авырулардан саклау, мульча ясау, минераль ашламалар кертү, чүп-чардан арындыру.

2.4.2. Берьеллык үләннәргә һәм икееллык үләннәргә су сибү җир тамырларының тирәнлегенә үтеп керсен өчен тигез булырга тиеш.